ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
САХАРОВСКОГО СЕЛЬСКОГО
ПОСЕЛЕНИЯ АЛЕКСЕЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АЛЕКСЕЕВСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
САХАР АВЫЛ ҖИРЛЕГЕНЕҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

с. Сахаровка

09.12.2021 № 18

**Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Сахар авыл җирлеге бюджеты кытлыгын финанслау чыганакларының баш администраторлары исемлеген раслау турында**

Россия Федерациясе Бюджет кодексының 160.2 маддәсендәге 4 пунктының дүртенче абзацы нигезендә Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының Сахар авыл җирлеге башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Сахар авыл җирлеге бюджеты кытлыгын финанслау чыганакларының кушымтада бирелгән баш администраторлары исемлеген расларга.

2. Әлеге карар, 2022 елга һәм 2023 һәм 2024 еллар план чорына Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Сахар авыл җирлеге бюджетын төзегәндә һәм үтәгәндә барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә карата кулланыла дип билгеләргә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

**Татарстан Республикасы**
**Алексеевск муниципаль районы**
**Сахар авыл җирлеге**
**башкарма комитеты җитәкчесе** **Л.В.Шаброва**

Татарстан Республикасы
Алексеевск муниципаль районы
Сахар авыл җирлегенең
2021 елның 9 декабрендәге
18 номерлы карары белән
расланган

Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Сахар авыл җирлеге бюджеты кытлыгын финанслау чыганакларының баш администраторлары исемлеге

| Бюджет кытлыгын финанслау чыганакларының баш администраторы исеме | Бюджет кытлыгын финанслау чыганакларының баш администраторы коды | Бюджет кытлыгын финанслау чыганагы төркеме, төркемчәсе, маддәсе һәм төре коды | Бюджет кытлыгын финанслау чыганагының төркеме, төркемчәсе, маддәсе һәм төре атамасы |
|---|---|---|---|
| Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының Финанс-бюджет палатасы | 501 | 01 05 02 01 10 0000 510 | Авыл җирлекләре бюджетларының калган башка акчаларын арттыру |
| Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының Финанс-бюджет палатасы | 501 | 01 05 02 01 10 0000 610 | Авыл җирлекләре бюджетларының калган башка акчаларын арттыру |